ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» ноябреннән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2025 елга республика бюджетына түбәндәге эчтәлекле «63,4 мең сум (спорт инвентаренә өстәмә финанслау)» сүзләрен өстәргә;

«Программаны финанс белән тәэмин итү» турындагы 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу өлешендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бүлү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 2549-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә өстәмә финанслау. (республика бюджеты) | - | - | - | - | 63,4 | 63,4 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Л.Еронтьевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов